**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ШИЛНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«2» ноябрь 2020 ел № 3/1

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге уставының 20, 95-97 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. «Җирлек Советының 2019 елның 24 сентябрендәге 37/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар проектын 1 нче кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә һәм аны халык тыңлауларына чыгарырга.

2. Расларга:

- «Җирлек Советының 2019 елның 24 сентябрендәге 37/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 2 нче кушымта нигезендә;
- «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы

«Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибен 3 кушымта нигезендә.

3. «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар проекты буенча халык тыңлауларын 2020 елның 16 ноябренә 18.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Шилнәбаш авылы мәдәният йорты залында түбәндәге адрес буенча үткәрергә дип билгеләргә: ТР, Тукай районы, Шилнәбаш авылы, Октябрнең 60 еллыгы ур., 2 йорт.

4. Түбәндәге составта халык тыңлауларын үткәрү буенча комиссия төзергә:

1) Гончарова О.А. – комиссия рәисе;
2) Шәрифуллина Ф.Х. – комиссия әгъзасы;
3) Портнова А.Ш. – комиссия әгъзасы.

5. Халык тыңлауларын үткәрү буенча комиссиягә халык тыңлауларын үткәрүне, күрсәтелгән карар проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә халык тыңлауларында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм совет каравына кертергә.

7. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе О.А. Гончарова

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 2 ноябрь 3/1 номерлы карарына 1 нче кушымта

Муниципаль берәмлек Советының 2019 елның 24 сентябрендәге 37/1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге уставының 20, 95-97 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Советның 2019 елның 24 сентябрендәге 37/1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

**1.1. <u>Уставның 5 статьясы 1 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 20 пунктны өстәргә:</u>**

«20) җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, территорияне планлаштыру буенча документлар яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр нигезендә үз белдеге белән төзелгән бинаны сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларына туры китерү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү турында Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә карар кабул итү;»

**1.2. <u>Уставның 5 статьясына түбәндәге өлешне өстәргә:</u>**

«3. «Шилнәбаш җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә, бу максатларга бүлеп

бирелгән матди ресурслар һәм финанс чаралары чикләрендә җаваплылыкка ия. Тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру дәүләт контролендә. «Шилнәбаш җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны контрольдә тоту шартлары һәм тәртибе федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә;»

**1.3. Уставның 6 статьясы 1 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 16 пунктны өстәргә:**

«16) полиция участок вәкаләтлесе вазыйфасын биләгән хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәрнең күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорына торак урыны бирү;»

**1.4. Уставның 31 статьясы 2пунтына түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:**

«Даими булмаган нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатына озынлыгы Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм тулаем алганда аена ике эш көненнән дә ким һәм алты эш көненнән дә артмаган чорга эш урынын (вазыйфасын) саклау гарантияләнә;»

**1.5. Уставның 60 статьясы 3 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:**

«3. Дисциплинар җәзаларны куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 2 ноябрь 3/1 номерлы карарына 2 нче кушымта

«Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәр язма формада төзәтмәләр таблицасы рәвешендә кушымта нигезендә:

| № | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтелгән текст | Төзәтүне исәпкә алып, карар проекты тексты | Төзәтмә авторы (фамилиясе, исеме, атасының исеме, адресы, телефоны, эш яки уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

түбәндәге адрес буенча җибәрелә: ТР, Тукай районы, Шилнәбаш авылы, Октябрьнең 60 еллыгы ур. 3А.;

почта аша: ТР, Тукай районы, Шилнәбаш авылы, Октябрьнең 60 еллыгы ур. 3А.;факс буенча (8552)37-53-36.

Тәкъдимнәр, карар проектын җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка игълан иткән көннән алып, 2020 елның 9 ноябренә кадәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: ТР, Тукай районы, Шилнәбаш авылы, Октябрьнең 60 еллыгы ур. 3А.;

почта аша: ТР, Тукай районы, Шилнәбаш авылы, Октябрьнең 60 еллыгы ур. 3А.; факс буенча (8552)37-53-36.

Гаризалар эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр халык тыңлауларын үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 2 ноябрь 3/1 номерлы карарына 3 нче кушымта

**«Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлаулары Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 20 статьясы нигезендә үткәрелә.

2. Үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашучылар булып Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Советына халык тыңлауларын үткәрү датасына кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча язма гариза биргән җирлек халкы тора.

3. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукыннан башка барлык кызыксынган авыл халкы катнаша ала.

4. Катнашучылар халык тыңлаулары башланырга 1 сәгать кала теркәлә башлый.

5. Халык тыңлауларына авыл җирлеге башлыгы рәислек итә.

6. Халык тыңлаулары рәислек итүченең катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлаулар үткәрү тәртибе турында хәбәр итүче кереш сүзе белән ачыла.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, искәрмәләрне исәпкә алу өчен, рәислек итүче тәкъдиме буенча секретариат җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында халык тыңлаулары секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән эшче төркем әгъзасы чыгыш ясый.

9. Чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашучылар, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

10. Халык тыңлауларында катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артмаска тиеш.

11. Халык тыңлауларында катнашучылар, чыгыш тәмамланганнан соң, рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.

12. Халык тыңлауларында катнашучылар халык тыңлаулары барышына кысылырга, аны өзәргә һәм үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

13. Халык тыңлауларын үткәргәндә тәртип саклау халык тыңлауларында катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Катнашучылар тарафыннан халык тыңлауларын үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче халык тыңлаулары барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, искәрмәләрне ачыклау өчен, халык тыңлаулары секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

16. Тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре халык тыңлаулары беркетмәсенә кертелә. Беркетмә билгеләнгән тәртиптә авыл җирлеге Советы материалларында саклана.

17. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

18. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә халыкка игълан ителергә тиеш.

19. Халык тыңлауларын үткәрүне оештыру һәм матди-техник тәэмин итү авыл җирлеге Советы тарафыннан башкарыла.